**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Заречный авыл җирлеге Юган поселогы торак пунктында гражданнар җыены КАРАРЫ**

«20» ноябрь 2024 ел № 12

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Заречный авыл җирлеге Юган поселогы торак пункты гражданнары җыены

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Заречный авыл җирлеге Юган торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 1 гр.инвалидлардан кала, балачак инвалидлары, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге бүлектә укучы студентлар, СВОда катнашучылардан кала, балигъ булган һәр кешедән 2025 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә һәм әлеге кертемнәрне түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- Юган торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту.

Халык җыенында рәислек итүче: Л.Г. Еливанова

Заречный авыл җирлеге башлыгы Л.Г. Еливанова